**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Улица Ключевая, дом 15, село Новое Ильмово, Черемшанский район, РТ, 423118

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА ЭЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Чишмә урамы, 15 нче йорт, Яңа Элмәле авылы,
Чирмешән районы, РТ, 423118

Телефон: (84396) 2-45-51, факс: (84396) 2-45-51 email: Nilm.Cmn2@tatar.ru

№ 127 29.05.2024 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 29 июнендәге 95 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 29 июнендәге 95 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.13 Сыйныф чины бирү көне дип сыйныф чины бирү турында карар кабул ителгән көн санала».

1.2. 4.21 пунктын бәян итәргә: «4.21 Муниципаль хезмәткәргә сыйныф чины бирү турында карар, Нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән сыйныф чины бирү турында тәкъдим сыйныф чины бирергә вәкаләтле органга яки җирле үзидарә вазыйфаи затына кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»

1.3. 5.3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге пунктча белән тулыландырырга: «13) яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә әлеге Нигезләмәнең 8.3 пунктының 2 пунктчасында каралган анкетада аңа билгеле булган мәгълүматлар үзгәрүе турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш (алга таба - анкетада булган мәгълүматлар).

1.4. 5.5 пунктның 8 пунктчасын бәян итәргә: «8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аларны бозу муниципаль

хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы белә торып ялган мәгълүматларны тапшыру, яисә аларны бозу муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәүне күрсәтүче документлар һәм (яисә) мәгълүматлар тапшырмау;»

1.5. 6.5 пунктын бәян итәргә: «6.5 Мәнфәгатьләр конфликты ягы булган муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.»

1.6. 6.7 пунктын бәян итәргә: «6.7 Яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрнең үзенә буйсынган муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килүе турында белгән муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве яллаучы вәкиле булган муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш.».

1.7. 7.7 пунктын бәян итәргә: «7.7. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (тормыш иптәшенең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри булса, яки тулы булмаган мәгълүматларны тапшыру муниципаль хезмәткәрне эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора, федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш.».

1.8. 8.4 пунктын бәян итәргә: «8.4 «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» гы Федераль закон һәм әлеге Кодекс нигезендә граждан тарафыннан муниципаль хезмәткә кергәндә бирелгән мәгълүматлар (анкетада булган мәгълүматлардан тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин. Аерым муниципаль берәмлекләрдә федераль законнар белән муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларны тикшерүгә өстәмә таләпләр билгеләнергә мөмкин.».

1.9. 19 нчы пунктның 11 нче пунктчасын бәян итәргә: «11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта граждан тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;».

1.10. 20.7 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Максатлы укыту турында килешү төзү конкурсында катнашу хокукына Россия Федерациясенең дәүләт телен белүче, тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белемне беренче тапкыр алучы һәм укуны тәмамлаганнан соң хезмәт мөнәсәбәтләре барлыкка килүгә китерә торган укучы яки башка килешү буенча йөкләмәләре булмаган гражданнар ия.».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Элмәле авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе
И.М.Җамалтдинов